**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«29» декабря 2025ел** **№ 176**

Теләче муниципаль районында 2026 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләменең иң чик индексы күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 ст. 4 өлеше, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак урын хуҗалары өчен торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау турында, торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча» приказы, Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 13 декабрендәге 1018 номерлы «2026 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» Указы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар һәм торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләменең иң чик индексы күләмен 15,1 процент күләмендә расларга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Б.М. Низамовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин